**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯҢА БҮЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«14» май 2022 ел № 3/2

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 08 декабрендәге 23/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 19 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 08 декабрендәге 23/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 29 статьяның 29.8 пункты 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр»;

1.2. 18 статьяның 18.1 пункты 2 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе М.С. Сагетдинов